| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СУГУШЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«СУГЫШЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 2 октябре** **№ 30**

**Сугышлы авыл җирлеге Сугышлы авылы территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьялары, Сугышлы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар КАРАР БИРДЕ:

1. 2018 елның 18 ноябрендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлеге Сугышлы авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. «2019 елда Сугышлы авыл җирлеге Сугышлы авылы чикләрендә урнашкан 18 яшькә җиткән һәр гражданнан 200 сум күләмендә үзара салым кертү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчалардан файдалану белән килешәсезме соравы буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

Урамнарны яктыртуны карап тоту;

Авыл җирлеге торак пункты чикләрендә юлларны карап тоту;

Авыл җирлеге торак пункты чикләрендә күперләрне ремонтлау.

« Әйе Юк».

3. Әлеге карарны Сугышлы авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Сугышлы авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге
башлыгы Ф.К.Янгирова